Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

9 февраль 2021 ел №27

Әлмәт муниципаль районы һәм Әлмәт шәһәре Башлыгының 2020 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре, 2021 елга бурычлар турында отчеты

Әлмәт муниципаль районы һәм Әлмәт шәһәре Башлыгы Т.Д. Нагумановның 2020 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре, 2021 елга бурычлар турында отчетын тыңлап фикер алышканнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы һәм Әлмәт шәһәре Башлыгының 2020 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре, 2021 елга бурычлар турында отчетын игътибарга алырга.
2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына отчет вакытында кергән тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар планын эшләүне һәм раслауны йөкләргә.
3. Отчетны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов